| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕАКСИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР АКСУ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

с. Большая Акса

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2021 ел № 12/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Зур Аксу авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә
үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.20021 ел, № 14-П карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 35/1 номерлы карары (2018 елның 28 мартындагы 46/1 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренең 135.13 пунктына " тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш һәм әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса;" сүзләрен өстәп үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Зур Аксу авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зур Аксу авыл җирлеге башлыгына йөкләргә .

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы: А.В.Храмов